


### Туган авыл

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш:
Бер кеше юк бер урамда...
Нинди тын һәм нинди буш.
(СәгыйтьРәмиев)

Әйе, нәкъ шундый минем авылым. Ул чит күзләрдән яшеренгәндәй, бик матур бер тыныч урынга урнашкан. Авылым ягалый Чирмешән елгасы ага. Яз көннәрендә шушы елгадан аккан бозларны, язгы ташуны күзәтүе генә дә ни тора бит. Җәйләрен елга буе безнең иң яраткан урыннарның берсенә әйләнә. Балалар эсседән качып, рәхәтләнеп су коена, балыкчылар кармак сала. Бакчачылар Аллаһы Тәгаләгә шушы нигъмәте өчен рәхмәтләр укып, суын кулланалар.

Авылымны һәр яктан урман-куаклыклар уратып алган. Яз көне алар яшеллеккә күмелеп, кошлар тавышына тула. Җәен җиләк-җимешкә, гөмбәгә бай була. Ә көзге якта алтынсу төсләргә бизәнеп, күзнең явын ала. Урман һәрвакыт безгә үзенең байлыкларын бүләк итеп тора. Авыл тирәсендәге болыннарны да телгә алмыйча булмый. Язын алар кыргый чәчәкләрдән ясалган чуар келәмгә әверелә, ә җәен бирелә сыер һәм сарык көтүлекләре йөри. Шушы болыннарга без чәчкәләр җыярга, ял итәргә йөрибез. Безнең авыл күлләргә дә бай. Алар зур түгел, ләкин бик матурлар. Яр буйларында камышлар һәм төнбоеклар үсә. Күлләрдә балыклар гына түгел, төрле бөҗәкләр һәм кошлар да яши. Монда үрдәк, каз һәм челәннәрне күрергә була.

Авылда тормыш тыныч һәм салмак кына бара. Монда һәркем бер-берсен белә, һәм һәркем авыр вакытта ярдәмгә килергә әзер тора. Кешеләр табигать белән бердәмлектә яшиләр. Тормышның гади шатлыкларын бәяли һәм үз гореф-гадәтләрен буыннан-буынга тапшыра беләләр. Авылда шаулап-гөрләп Нәүрүз, Сабантуй кебек милли бәйрәмнәр ел саен кабатланып килә. Рамазан, Корбан гаетләре кебек дини бәйрәмнәр зурлап уздырыла. Шушы чаралар аша без – яшь буын үзебезнең йолаларыбызны, динебезне гамәлләр аша күреп, белеп үсәбез.

Авылга күченеп кайтуыбызга мин бик шат. Монда мин үземне иркен һәм тыныч хис итәм. Авыл – ул минем өчен чын мәгънәсендәге Ватан, йөрәккә якын урын. Авылымның һәрбер сукмагы һәм агачы миңа кадерле. Киләчәктә дә мин авылымны ташлап китәргә теләмим.

Шушы изге айларда мин авылымның алдагы көннәрдә дә чәчәк атуын теләр идем. Тирә-яктагы авыллар шикелле кызганыч хәлгә калмасым иде минем авылым. Авыл өчен яның-көеп йөрүче кешеләр күбәйсен, урамнарында бала тавышлары беркайчан да туктамасын иде. Мәңге яшә, минем кадерле почмагым!

*Ләйсән Закирова, VII сыйныф укучысы*

### Әбиемнең туган авылы

Мин һәр җәйне әбием белән үткәрдем. Ул яшәгән өй агач бүрәнәләрдән иде. Кечкенә генә бакчасында күп төрле чәчәкләр үстерә иде. Миңа аларны өзәргә кушмый, хәтта тотынсаң да матур үсмәсләр дип кисәтә иде. Әбинең бакча артында болынга җиләккә дә йөрдек. Җиләк җыйган вакытта үзенең бала вакытларын искә төшереп сөйләде. Әниемнең дә бала чагын сөйләп җибәреп, аның бала чактагы шуклыкларын яратып искә ала торган иде. Шундый истәлекләрне тыңлаганда, җиләк тә тиз җыелды. Өйгә кайтанда әбинең песәйләре безне көтә иде. Мин алар белән уйный идем. Әби үзе дә аларны бик ратты.

Әбиемнең туган авылы – минем кечкенә чагымның матур истәлекле урыны. Әбиемнең төрле хикәятләре, җиләккә йөрүләр, кечкенә генә агач өе – минем өчен һәрвакыт тыныч һәм күңелле урын булды.

*Кәримә Сафиуллина, VII сыйныф укучысы*

### Кошларны каршы алабыз



Яз җиту белән ел саен сыерчык ояларын кайгыртабыз. Башка елларда Нәүрүз бәйрәменә әзерли идек бу ояларны. Соңгы ике елда, Рамазан аена туры килгәнлектән, Нәүрүз бәйрәме үткәрелми калды. Быел бу күркәм гадәтебезне Гает алдыннан башкарып чыктык. Язгы каникулга китер алдыннан мәктәптә сыерчык оялары ясаучылар билгеләп үтелде. Барлыгы 14 оя ясап, язгы кунакларыбыз өчен урнаштырдык. Шулай итеп, туган ягыбыз өчен тагын бер матур эш башкардык. Табигатькә битараф булмаучыларга бүләкләр Рамазан гаетендә тапшырылачак.

*Ләйсән Закирова, VII сыйныф укучысы*

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин

# Мәктәп хәбәрчесе

**№3 (№64) март 2025 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газете*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

*/Мөхәррир минбәре/*

### Тәнкыйди фикерләүнең әһәмияте




Газитебезнең бернчә санында туган тел язмышы, балаларның сөйләме турында язып үткән идек инде. Бу мәсьәлә һаман да әһәмиятле булып калганлыктан, мәктәп директорының тәкъдиме белән быелгы Рамазан аен иҗади ай дип игълан иттек. Ай дәвамында, Рамазан гаетенә кадәр укучыларга булдыра алган кадәренчә иҗади эшләр белән шөгыльләнергә кушылды: кемнәрдер бәйрәм күргәзмәсенә кул эшләнмәләре ясый, башкалар хикәя яки шигырь язарга тиеш. Бу чараның максаты – балаларыбызның сөйләм телен һәм һөнәри осталыкларын үстерүгә йогынты ясаудан гыйбарәт иде.

Күпме генә сөйләп һәм аңлатып торуга карамастан, хәзерге буын балаларның сөйләме күңелләрне борчый. Үзара аралашканда да, дәрестә җавап биргәндә дә, укучыларның күп өлешеүз фикерләрен бирергә комачаулаган "киртәләргә" еш очрый. Бу "киртәләр" балаларда сүз байлыгының ярлылыгыннан килеп туа. Сүзен әйтә алмыйча интегү аркасында укучының тәнкыйди фикерләве дә тоткарлана. Ә тәнкыйди фикерләүкешедә мәгълүматны кабул итү тәэсирен көчәйтүче, кызыксыну уятучы, җаваплылыкны, үзаңны формалаштыручы төп факторларның берсе. Шуңардан башка белем сыйфатын күтәрү, бергәләп эшләргә өйрәнү, үзеңне замана белән бергә атлаучы шәхес итеп тою мөмкин түгел. Уйлый, фикер йөртә, нәтиҗә чыгара белүчеләр һәр заманда да югары бәяләнгән. Укытучылар һәм эти-әниләрнең төп максаты – балаларыбызны милләтнең киләчәге, илнең тоткасы булырлык шәхесләр итеп тәрбияләү. Шул юнәлештә без бергә һәм бердәм булып, җиң сызганып гамәл кылырга тиешбез!

Инде сүз башыбызга әйләнеп кайтканда, "Мәктәп хәбәрчесенең" бу саны укучыларыбызның Изге Рамазан ае дәвамында иҗат иткән хикәя, кроссворд һәм шигырь тәкъдим итүгә багышлана. Башлангыч сыйныф укучылары арасында бәйрәмгә кул эшләнмәләре әзерләүчеләр булды. Читтә яшәүче авылдашларның балалары да бу чарага кушылсын дип мөрәҗәгать иткән идек, алардан да бернчә укучы катнашты. Рамазан аеның нигъмәтләрен сурәтләгән, туган авылларына ярату белдергән, эти-әние хөрмәтләгән, дуслык кадерен исбатлаган сүзләр балаларыбызның күңелләрендә уелып калыр дип ышанасы килә.

*Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир*

### Бәйрәм белән, хөрмәтле хатын-кызлар!




Хөрмәтле әниләр, апалар, сеңелләр! Без Сезне 8март – Халыкара хатын-кызлар көне белән котлыйбыз! Хатын-кыз яз кояшы төсле булганга, бәйрәме дә язгы айның беренчелегендәдер. Шул кояш ничек якты, җылы булса, әниләр дә шулай. Якты нуры белән дөньяны яктырта, җылылыгы белән күңелгә үтеп керә. Өйләрне ямьле, ризыкларны тәмле итә. Кулыгыздан гөлләр тамызып, гаиләгез, балаларыгыз өчен барысын да эшлисез сез, Әниләр!

Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, кояштай озын гомер телибез! Хатын-кызга хас сабырлык, тыйнаклык сезне һәрчак бизәсен. Назлы елмаюыгыз күңелләрне җылытсын! Ягымлы карашыгыз һәркемгә көч өстәсен! Теләкләр чынга ашып, гаиләләребезне җылытып, тормышыбызны матурлап яшәгез!




*"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе*

### III чирек нәтиҗәләре

*/Рәсми хәбәрләр/*

2024-2025нче уку елының III чиреге тәмамланды. 39 укучының 37 сенә билгеләр чыгарылды. Белем сыйфаты 100%, өлгереш 56,7 % тәшкил итте. Уку буенча отличниклар: II сыйныфтан **Хәйруллин Мансур**, III сыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә**, IV сыйныф укучылары **Камалов Илнур** белән **Закиров Инсаф**, V сыйныфтан **Нурматова Асия**, VII сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, VIII сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил**. Язгы каникуллар 22 марттан 1 апрельгәчә дәвам итәчәк.

*Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары*



**/Безнең уңышлар/**

## Иҗади бәйгеләрнең нәтиҗәләре

Ел саен “Без бергә” дип аталган фестиваль уза. Быел да әлеге чара иҗади сәләтләрен күрсәтергә әзер булган яшьләрне җыйды. Мәктәбебез укучылары район уздырган турда уңышлы чыгышлар ясап, һәр номинацидә урыннар алдылар.

Инде җиңүчеләребезне билгеләп үтик:

- "Халык ансамбле" номинациясендә VI сыйныф укучысы **Донсков Артур** белән IV сыйныфтан **Закиров Инсаф**– I урын;
- "Иҗади гаилә" номинациясендә **Гыйниятуллиннар гаиләсе** – III урын (V сыйныф укучысы **Гыйниятуллин Азамат** катнашында);
- "Декоратив-гамәли эшләнмә" номинациясендә IV сыйныф укучысы **Закиров Инсаф**– III урын;
- "Иң яхшы күргәзмә экспозициясе" номинациясендә IV сыйныф җитәкчесе **Хәйруллина Рузилә апа**– II урын;
- "Театральләштерелгән иҗат" номинациясендә **Нургалиевлар гаиләсе** "Творческий подход" грамотасы белән бүләкләнде (IX сыйныф укучысы **Нургалиева Ләйлә** катнашында).

Укучыларыбызның сәхнә осталыклары артсын, нәфис сөйләм күнекмәләре баесын, мәктәп исемен тагын да зуррак сәхнәләрдә яңгыратсыннар дип телəп калабыз.

12 март көнне районыбызның 3нче мәктәбендә "День родного русского языка" дип аталган конкурсның оста шигырь сөйләүчеләр бәйгесе булып узды. Бу чарада катнашкан безнең мәктәп укучыларыннанVII сыйныфтан**Закирова Ләйсән** җиңүче исеменә лаек булды. IV сыйныфтан **Сафиуллина Гөлсем** һәм IX сыйныфтан **Шичкин Али** сертификатлар белән бүләкләнделәр.

14 мартта район үзәгендә "Живая классика" конкурсының муниципаль туры узды. Бу чара укучыларның нәфис сөйләм осталыгын билгеләде. Укучыларыбыз бу бәйгедә дә сынатмадылар. VIII сыйныф укучысы **Вәлиев Ибраһим** җиңүче, VII сыйныфтан **Насыйрова Кәүсәр** призёр исемен алуга ирештеләр. Vсыйныфтан **Нурматова Асия** катнашучы сертификаты белән бүләкләнде.

Укучыларга зур тырышлыклары өчен рәхмәт белдерәбез!

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***





## “Сәйяр” бәйгесендә җиңдек!

Берничә ел март аенда укучылар белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырылган “Сәйяр” балалар һәм яшүсмерләрнең республика театр фестивалендә катнашып киләбез. Алдагы елларда да алдынгы урыннарны алуга ирешкән идек. Быел яшь драматургларның әсәрләрен сайларга диелгәч, озак эзләнеп, Дилә Мөхәррәмованың “Без уcкәндә биш кыз идек” дигән драмасына туктадык. Әсәр нәкъ бүгенге көн кадагына суга торган темаа бирә. Авылда төп нигезләр тарала, аларны кире торгызу проблемасы ята. Күңелгә якын булган әшебезнең нәтиҗәсе тагын да кызыклырак булды. Безнең театр түгәрәгенә йөрүчеләр сәхнәләштергән спектакль 10-11 сыйныф укучылары куйган конкурс эшләре арасында беренче урынга лаек булды. Узган елларда Мәгариф министрлыгы грамотасы белән бүләкләнсәк, быел 20 мең күләмендә акчалата премиягә ия булдык. Бу акча мәктәпкә милли киемнәр тектерүгә тотылачак.

***Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**/Котлыйбыз!/**



Март аенда туган көннәрен билгеләп үтүче укучыларыбыз II сыйныфтан **Хәбибрахманова Асияне** (25.03),V сыйныфтан **Хусенов Диманы** (14.03),VII сыйныфтан**Әхсәнова Мәдинәне** (11.03), VIII сыйныфтан **Вәлиев Ибраһимны** (17.03) чын күңелдән котлыйбыз. Дусларыбызга сәламәтлек, укуларында уңышлар телибез!

2 март көнне 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче хөрмәтле укытучыбыз **Гафиятуллина Фәнүзә апаны** гомер бәйрәме белән котлап, ныклы сәламәтлек, мактаулы эшендә зур уңышлар, барлык уй-хыялларының тормышка ашуын телибез!



## Иҗади Рамазан

**/Безнең бәйрәмнәр/**

Рамазан ае безнең өчен башка айлардан күпкә аерыла. Бу айны без һәр елны аерым шатлыклары булганга көтеп ала идек. Ә быелгы Рамазан исә, үзенчәлекләре булгач, тагын да бәйрәмчәрәк төс алды. Ураза тотучы укучылар елдан-ел арта барганлыктан, быел мәктәптә эшләүче апалар мәктәп ашханәсендә ифтар ашлары уздырдылар. Ифтар алдыннан төрле мавыктыргыч әңгәмәләр, викториналар һәм квестлар оештырдылар.

Рамазан ае башлануга ук мәктәп директоры Рафик абый бу айны “Иҗади Рамазан” дип игълан итте. Шулай ук, ерактан кайтучы нәни дусларыбыз – сиерчыкларга оя ясарга кушты. Элек бу биремне без Нәүрүз бәйрәменә үти идек. Рамазан ае дәвамында күп укучылар Рамазан, Туган як, Туган тел, Әниләр темасына шигырь-хикәяләр яздылар, кул эшләнмәләре ясадылар. Сиерчыкларны да оялар ясап элеп каршы алдык. Гаеткә кадәр бу эшләрне төгәлләдек.

Гает бәйрәме чарасы мәчет йортында мәктәп ярминкәсе белән башланып китте. Укучылар өйләрендә әзерләп килгән тәмле-татлы ризыклар әзерләп сатты. Авыл халкы да, күрше авыллар да балалар саткан товарны теләп алдылар.

Ярминкәдәге товарлар сатылып беткәч, бәйрәмебезнең икенче өлеше – иҗади Рамазанга йомгак ясау өчен мәчет эченә кердек. Иң элек Хафизов Илфат азан әйтте. Азан яңгыраганнан соң, үзләренең хикәя һәм шигырьләрен сөйләүчеләргә сүз бирелде. Бу биремне дә күп укучы теләп башкарды. Аннан соң кул эшләре бәйгесе дә бар иде. Бу эштә Хабибрахманова Асия, Хәйруллин Мансур, Сафиуллина Гөлсем, Закиров Инсаф, Насырова Кәүсәр осталыкларын күрсәттеләр. Башваткычлар ясаучы иптәшләребез дә бар иде. Авыл укучылары гына түгел, кунакка кайтып йөрүче балалар да бу өлештә теләп катнаштылар. Аларның һәрберсе игътибарга алынды, бүләкләнделәр. Бүләкләр әле тәрәвих намазларын калдырмаучыларга бик күп итеп алынган. Гомумән, Рамазан ае шатлыклы да, бүләкле дә булды.

Гает бәйрәменә махсус рәвештә казан кайтартылды. Шул яңа казанда минем әтием Әнвәр мәчет йортында учакта пылау пешерде. Бәйрәмнең ахыргы өлешендә үзенең пылавы белән ул һәрбер кунакны сыйлады. Укытучы апалар өстәл әзерләгәннәр иде. Бәйрәмгә килгән һәркем гает коймагыннан һәм пылаудан авыз иттеләр.



Гомумән алганда, укучыларыбыз да, авылдашлар һәм читтән кайткан кунаклар да бәйрәмдә оештырылган чаралардан канәгать калдылар. Бу айда башкарган һәрбер гамәлебез изге теләктән булып, киләчәгебез өчен дөрес юл күрсәтер дип ышанам.

***Зәйнәп Нурматова, XI сыйныф укучысы***

### Рамазан ае җитте

Күңелләргә сафлык өстәп,
Килеп җитте Рамазан.
Мәчетләрдә кабат-кабат
Ишетелә моңлы азан.

Һәр кеше бу изге айда
Эшли бары изгелек.
Күңелнең түренә үтә,
Эшләргә әнди игелек.

Өйләрдә артканнан-арта
Сәхәр,авыз ачулар
Олысы да,кечесе дә
Дингә ныграк тартыла.

Мөнә ураза гаете –
Көтеп алган зур бәйрәм.
Күңелләргә шатлык өстәп
Йөрәк түрен биләгән.

***Руфинә Гафиятуллина,***
***III сыйныф укучысы***

### Котлы булсын Рамазан!

Аллаһының зур бүләге
Сафландырып җаннарны.
Гаилә белән бергәләшеп
Көттек без Рамазанны.

Котлы булсын Рамазан!
Сынаулы ай булса да,
Без бер дә сынатмабыз.
Шатлык иңеп торганга.

Ашау-эчү тыелса да
Иман белән туярбыз.
Ураза сынау булса да,
Без бер дә бирешмәбез.

Аллаһ биргән тугры юлдан
Һич читкә тайпылмабыз.
Иманга куәт булган
Котлы булсын Рамазан!

***Әхмәт Гәлиуллин,***
***VIII сыйныф укучысы***

### Изге ай

Җитте изге Рамазан
Яңгырый моңлы азан.
Олысы -кечесе ашыга
Тәрәвих намазына.

Таң вакытыннан алып,
Өйләрдә ут кабына.
Барлык мөселман ашыгып,
Сәхәр ашарга тора.

Рамазан ае –изге ай
Әйдә, уян син дускай,
Кушылып кит син дә безгә
Дога укы, гыйлем ал.

Изге Рамазан айлары
Килә ул һәрбер елда.
Кыл игелек, ит изгелек
Алырсың савабын да.

***Ләйлә Нургалиева,***
***IX сыйныф укучысы***

### Авылым Рамазаны

Рамазан әле җиткәчтен
Һәр кем гыйбадәт кыла
Ахшам намазы белән
Ифтарны көтеп ала.

Затлы,тәмле кичке ашлар
Гаиләне бергә җыя
Моңлы азан тавышы
Тәравихка чыкыра.

Татлы йокыны бүлеп
Һәркем сәхәргә тора
Тәрәзәләрдә ут күреп
Күңелгә шатлык тула.

Елдан-ел бу мөбәрәк айга
Хөрмәт гел арта бара
Нәни балаларга кадәр
Барысы ураза тота.

***Кәүсәр Насыйрова,***
***VII сыйныф укучысы***

### Түбән Майнам

Туган авылым – газиз Түбән Майнам
Күпме сукмакларың таптадым.
Кай җирләрдә генә яшәсәм дә
Синнән якынракны тапмамын.

Синдә генәдер минем язмышым
Тәүге хисем, изге уйларым.
Тәпи басып, зу үскәчтән дә мин
Синнән аерыла алмам, авылым.

Онытмамын туган авылымны
Йөрәк түрләрендә сакларммын.
Изге уйлар белән сугарылган
Горур кызын булып атлармын.

***Хәнифә Хәбибрахманова,***
***VIII сыйныф укучысы***

### Рәхмәт, әнием

Яшәү бәхетен миңа бүләк иткән
Иң кадерле, газиз, әнием
Балачакның матур мизгелләре
Синең тырышлыгың, әнием.

Йөрәгеңнән чыккан бу назлы сүз
Саклый мине тормыш юлында
Рәхмәт, сиңа, мөмкинлеге өчен
Назлануың өчен куеныңда.

Һәр аткан таң өчен рәхмәт сиңа
Һәрбер сүзең өчен мең рәхмәт
Бу дөньяда син дип яшәүләре
Әнием-бәгърем, сиңа бик рәхмәт.

***Настя Сафеева,***
***VII сыйныф укучысы***

### Я Аллам!

Син минем тормышым ,
Син минем яклаучым.
Я, Аллам! Я, Раббым,
Бәладән саклаучым.

Ышанычым син минем,
Таянычым син минем.
Я Аллам! Я Раббым,
Бердәнберем син минем.

Чын күңелдән, Аллам, сине сөеп,
Укыйм мин дога, сүрәләр.
“Ләә иләһә илләллаһү”– диеп
Шөкер кылып яшик, кардәшләр!

***Мансур Хәйруллин,***
***III сыйныф укучысы***

### Туган як

Түбән Майна авылыматурҗирдә,
Яшеллеккәчумган тирә-як.
Күлләрендә бака тавышлары,
Әүрмандакошларсайрыйлар.

Таулар, кырлар, киңболыннар буйлап
Дуслар белән бергә йөргәндә
Якты кояш тәнне генә түгел,
Җаннарны да гүя җылыта.

Балык тотабыз без Чирмешәндә,
Кармакларны салып елгага.
Чума-чума суда коенабыз.
Шулай булсын һәрбер заманда.

Табигать бай җиләк-җимешләргә,
Җыябыз без тутырыпчиләккә.
Туган якка бик рәхмәтлебез без,
Аның белән бергә гомергә.

***Туктамышев Таһир, Казан шәһәре***
***VII сыйныф укучысы***

### Туган җирем

Туган җирем, туган авылым минем
Кайтырмын мин сиңа тагын бер
Чәчәк аткан яшел болыныңда
Йөрермен мин әле тагын бер.

Туган авылыма кайтуымны
Көтәр инде әнкәй сагынып,
Шулай булгач әнием янына
Ничек кайтмыйм инде ашкынып?

Балачагым, иң күңелле чагым,
Туган авылымда үтте бит
Ничек инде аны сагынмыйсың?
Тирә-күршеләрем, туганнарым
Барда мине якын итте бит.

***Мәдинә Әхсәнова,***
***VII сыйныф укучысы***

### Рамазан шатлыгы

Рамазан ае кергәч,
Мин бигрәк тә шатландым.
Уразаны калдырмаска
Һәр көнне мин уйладым.

Сыйныфташлар сорыйлар:
"Нәрсәгә ул кирәк?" – дип.
Җавап бирдем мин аларга:
"Саваплы гамәл ул" – дип.

Әни белән сәхәр ашау
Сагындырыр үскәч тә.
Уразалар кабул булсын
Дигән теләк күңелдә.

Киләсе Рамазаннар да
Шундый күңелле булсын.
Гаиләм, туганнарым белән
Уразалар тотарга язсын.

***Хаметов Данияр, Казан шәһәре***
***VIII сыйныф укучысы***



### Рамазан хикмәтләре

Әле кайчан гынә Рамазан аена аяк баскан идек, инде менә соңгы ун көне генә калып бара. Ураза тоту авырмы дип сорасалар, мин беркү вакытта “юк” та, “әйе” дә дип әйтер идем. Чөнки күпмедер вакыт ашамыйча торуның бер дә авырлыгы юк. Әмма дә ләкин, ураза тоту, авызыңа ризык капмаудан гына тормый шул.

Ураза тотуның тирән мәгънәсе кулыңны, телеңне, күзеңне, колагыңны ярамаган эшләрдән тыю. Дөрес кулланмаган очракта, тел – безнең дошманыбыз ул. Юкка гына әби-бабаларыбыз "Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел" – дип әйтмәгәннәрдер. Ураза тотам дип, телең белән кешеләрне рәнҗетеп йөрсәң, алар белән бәхәсләшсәң, уразагың кыйммәте югала. Уилл Боуэн исемле дин әһеле, кешеләрнең үз-үзләрен тотышын өйрәнгәннән соң, адәм балаларының күп вакытларын зарланып, гайбәт сатып, башкаларны тикшереп уздыруларын ачыклаган. Аның фикеренчә, тормышыңны яхшы якка үзгәртәсең килсә, 21 көн буе зарланмыйча, гайбәт сүз сөйләмичә, беркем белән дә ачуланышмыйча яшәргә кирәк икән. Уилл Боуэн башкарган эшнең нәтиҗәсенә үзегез дә шаккатырсыз. Аның программасы аша узган бөтен кешеләр дә үзләрен яхшы якка үзгәрткән!

Аллаһы Тәгалә безгә уразаны фарыз итеп биргән. Ураза – үзебезнең кимчелекле якларыбыз өстендә эш алып бару өчен менә дигән вакыт ул. Без, мөселманнар 21 көн генә түгел, ә 29-30 көн дәвамында тиешенчә ураза тотсак, яхшы якка үзгәрү өчен зур мөмкинлекләр алачакбыз. Тормыштагы, кешеләрдәге уңай якларны күрергә өйрәнәчәкбез.

***Зәйнәп Нурматова, XI сыйныф укучысы***

### Дога

Кечкенәдән әнием мине
Үстерде дога белән.
Хәзер мин дә, Сөбханалла,
Бик күп догалар беләм.

Раббыбыз белән һәр көнне
Дога аша сөйләшәм.
Яшерен серләремне дә
Аның белән серләшәм.

Авыр чакта Раббыбызга
Дога укып ялварам.
Укыган догаларымны
Ишетердип инанам.

Кыйблага таба юнәлеп
Әйтәм дога сүзләрен.
Раббым Аллаһ, ишет мине
Кабул булсын теләгем

***Асия Нурматова,***
***V сыйныф укучысы***

### Рамазан ничек үтте

Изге Рамазан килде
Ул безгә савап бирде.
Иртән торып кичкә кадәр
Ураза тотарга иде.

Уразаны бер ай тотып,
Үзенне тәртипле тотарга.
Ифтардан мәчеткә барып,
Намазларны укырга.

Без мәчеттә булганда
Корьән тыңлап торабыз
Корьән тыңлап бетергәч
Без намазга басабыз.

Изге Рамазан аенда
Аның соңгы көнендә
Гает бәйрәмен уздырабыз
Мәчетебез түрендә.

***Али Шичкин,***
***IX сыйныф укучысы***

### Дуслар булсын янымда

Дуслар булса, рәхәт инде,
Дуслар безгә гел кирәк.
Минем өчен бит дусларым
Һәрвакыт булды терәк.

Урамда да, мәктәптә дә
Алар һәрчак янымда.
Якын дуслар янәшәмдә
Гел булып торсын гына.

Дуслар булгач, авыр түгел
Егылгач та торырга.
Дуслар белән генә мөмкин
Яхшы тормыш корырга.

Дус һәм тату булып бергә
Яшик бергә гомергә!
Сыналу өчен генә бит
Без бит килгән бу җиргә.

***Дима һәм Стас Хусеновлар,***
***V, VIII сыйныф укучылары***

### Әнием!

Синнән дә яктырак
Синнән дә яхшырак
Матуррак кеше юк
Бөтен Җир йөзендә.

Китсәм дә читләргә
Әнием син шикләнмә
Талпынып яныңа
Кайтырмын ерактан.

***Зөлфәт Җамалетдинов,***
***VI с.***

### Бүләкле Рамазан

Рамазан безгә килде
Бүләкләр алып килде
Ураза тотып, сабыр итеп
Ифтар без көтәбез
Ә ифтарны ашагачтан
Тәрәвихка китәбез.

***Абдулла Хәбибрахманов,***
***VI с.***

### Авыл – тылсымлы җир

Җанга рәхәт булган җир ул авыл. Авылның агачлары, сулары, чишмәләре, өйләре минем хәтеремнән беркайчан да чыкмас. Авылда яшәү – ул иң зур бәхет. Авылда бик күп нәрсәгә өйрәнеп була. Эшкә, дуслыкка, мәрхәмәтлелеккә. Авылда гына син табигать белән бергә тыгыз бәйләнеш белән яшисең. Авылның урманнары ул бөтенләй бүтән дөнья. Андагы матурлыкны сүзләр белән генә тасвирлап булмый. Авыл жире – тылсымлы җир.

***Камил Төхвәтуллин, VII сыйныф укучысы***

### Мин татарча сөйләшәм

Матур гына елмаеп
Мин татарча сөйләшәм.
Шулай дус,туганнарга
Мин бәхеттә өләшәм.

Әбием белән бабаем
Татар канынннан туган.
Әнием мине яратып
Матур исемне куйган.

Татар улы мин, татармын
Татар нурын югалтмам,
Күп телләрдә сөйләшсәм дә
Ана телен онытмам!

***Илнур Камалов,***
***IV сыйныф укучысы***

### Туган телне өйрәндем

Мин шәһәрдә яши идем,
Күчеп кайттык авылга.
Күрше авыл мәктәбенә
Туры килде барырга.

Яңа дуслар, укытучылар
Каршы алды үземне.
Идән юучы апа да
Яратмады телемне.

Ләкин, мин дә сынатмадым,
Авырсынмадым бер дә,
Өйрәндем бит, туган телдә
Сөйләшәм хәзер мин дә.

***Рамазан Мифтахов,***
***V сыйныф укучысы***

### Әнием

Син, әнием, минем өчен
Бу дөньяда бер генә.
Синең якты йөзләреңнән
Өйгә нурлар бөркелә.

Тыңлап бишек җырларыңны
Елавымны басканмын.
Телем дә бит тәүге тапкыр
“Әннә” диеп ачканмын.

Кая барсам, кайда йөрсәм
Әнкәй минем күңелемдә.
Ниләр генә эшләсәм дә
Яши минем йөрәктә.

***Вәсилә Залиева,***
***VIII сыйныф укучысы***

### Бәйрәм бүген

Бәйрәм бүген, Гает көне
Рамадан ае үтте.
Ураза тоту, ашамаулар
Сизелми үтеп китте.

Тәравихлар, сәхәрләр
Телне саклау, тыйнаклык
Барсы да безгә файдага
Һәммәсе бик зур байлык.

Мәрхәмәтлек калсын бездә,
Рамазан белән китмәсен.
Күңелләрдә бәйрәм рухы,
Гает мөбәрәк булсын!

***Вәлиев Ибраһим, VIII с.***

### Мин мөселман баласы

Әби-бабай кочагында
Үсүче малай бит мин.
Әдәп-әхлак гадәтләрен
Белүче малай бит мин.

Әби - бабай, әти- әни,
Авылым, телем минем,
Бу сүзләрне кечкенәдән
Якын итә күңелем.

Бабаем да, әтием дә
Ислам динен өйрәтә.
Мин мөселман баласына
Динне белү кирәк лә.

***Азамат Гыйниятуллин,Vс***

### Авылымны яратам

Яратам мин авылымның
Кырларын, болыннарын.
Яшел, чиста урманнарын
Балыклы елгаларын.

Яратам мин авылымның
Песиен дә, этен дә.
Рәхәт бирә йөрәгемә
Майлы, пешкән ите дә.

Яратам мин авылымны
Рәхәт инде, чын менә!
Авылымның тузаны да
Якын минем күңелемә

***Ирек Хафизов, V с.***

### Изге аебыз

Күңелләрне сөендереп
Изге аебыз җитте.
Гаиләбез инде күптәннән,
Сөенеп аны көтте.

Әй шатлык та иртә белән
Сәхәргә торулары.
Әти, абый белән бергә
Ифтарга барулары.

Мәчет манарасыннан
Яңгырый азаннары
Күңелемә рәхәт бирә
Тәравих намазлары.

***Халит Гәлиуллин, V с.***